СӨЙ ГОМЕРЕҢНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

25 октябрь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 121 (8133) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ИРТӘГӘ - АВТОМОБИЛЬ ТРАНСПОРТЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КӨНЕ

## Бәйрәмегез белән!

Күркәм традиция буенча октябрьнең соңгы якшәмбесендә автомобиль транспорты хезмәткәрләре көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан район хакимияте, халык депутатларының район Советы сезне, хөрмәтле автотранспортчылар, һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелдән котлый.

Бүген без сезнең коллективлар көче белән пассажир һәм йөк күчерүләр - чимал, төзелеш материаллары, игенчелек һәм терлекчелек продукциясе ташуларның тулы күләмдә гамәлгә ашырылуын таныйбыз. Җитештерү күләменең артуы, коллективларның эшчәнлек дәрәҗәсе, кешеләрнең кәефенең күтәренке булуы сезнең үз һөнәри бурычыгызны ни дәрәҗәдә үтәвегезгә бәйле. Шунысы куанычлы, бүгенге катлаулы заманда да сез техник дәрәҗәне күтәрү, профессиональ әзерлегегезне үстерү, эшкә бирелгәнлек, хезмәт дисциплинасын яхшырту, матди - техник базаны ныгыту һәм үстерү өстендә армый - талмый эшлисез һәм киләчәктә дә шуңа йөз тотарсыз дип ышанабыз.

Хөрмәтле автомобиль транспорты хезмәткәрләре! Район җитәкчелеге исеменнән сезгә җәмгыятебез өчен чиксез кирәкле хезмәтегездә зур уңышлар, бәхет, сәламәтлек, игелек телибез.

Ф.СИБАГАТУЛЛИН,
халык депутатларының район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы.

## ГОМЕР БУЕ ЮЛДА

Шофер - иң массакүләм һәм авыр һөнәрләрдән санала. Шоферларга юл кыенлыкларын да, һава көйсезлекләрен дә күпме кичерергә туры килә бит. Бу урман ташучы шоферларга аерата кагыла. Николай Иванович Макаров гомер буе шул эштә булса да, авырлыклардан зарланмый. Вахта машинасы баранкасы артына ул 1966 елда утырган иде. Хәзер 15 ел инде урман аланнарыннан Октябрь урман хуҗалыгы складлары - Норлат, Тумба яки Бутаихага агач ташый. Куәтле «КамАЗ» аның исәбендәге 4 нче машина инде.

Хәерле юллар сезгә, Николай Иванович!

**Н.АЗИЗОВ фотосында урманчылыкның Чулпан автохуҗалыгы шоферы Н.И.Макаров.**



Безнең әңгәмә

## И.Вәлиуллин:
# « ДИСЦИПЛИНА - ИҢ МӨҺИМЕ»

*«Безнең идарәнең нефть чыгару объектлары республиканың 6 районында урнашкан. Әгәр дә бүген төп хезмәт күрсәтүчебез - технологик транспорт идарәсе эшенең берәр чылбырында чатаклык туса, нефть чыгару параличлана дигән сүз. Шөкер, моңа юл куелганы юк. Алай гына да түгел, тулаем идарә нефть чыгаручыларының көйле эшләвендә УТТ автотранспортчыларының өлеше бик зур»*

**(«Норлатнефть» НГДУсы начальнигы М.М.Хуҗин белән әңгәмәдән).**



**Районда гы иң эре автотранспорт предприятиесе булган Норлат технологик - транспорт идарәсе (УТТ) җитәкчесе И.Г.Вәлиуллин белән бүгенге көндә оешманың эшчәнлеге турында сөйләшү теләге дә шул әңгәмәдән соң туды. Ул автотранспортчыларның һөнәри бәйрәменә туры килде.**

**- Исхак Гарифуллович, Сез җитәкләгән идарәдә эшләр ничек тора?**

- Заманалар катлаулы, һәр адымда түләмәүчелек, акчасызлык тәртәгә сугып торганда беркемгә дә җиңел булмавын ачык аңлаганга зарланырга җыенмыйм. Шөкер, әлегәчә авырлык белән булса да кыенлыкларны җиңә барабыз. Идарәнең һичкайчан эш фронтына кытлык сизмәве дә күп нәрсә турында сөйли. НГДУның нефть чыгаруга бәйле бөтен эше - торбалар салу, ремонтлау, төзелеш, халык күчерү, йөк ташу - болар барысы да безнең идарә автотранспортчыларының якыннан катнашы белән башкарыла. Элегрәк моңа Норлат - Октябрь АТПсы техникасы тартылса, соңгы елларда аларның хезмәте тулысынча кире кагылды. Ни өчен дигәндә, УТТ үзе генә дә идарәнең автотранспортка булган ихтыяҗын тулы канәгатьләндерә.

**- Техника саны артуга бәйлеме бу, әллә аларның җитештерүчәнлеге күтәрелүгәме?**

- Тегесе дә, бусы да бар. Иң элек шуны әйтәсем килә: идарәнең техника паркы ел саен артуга бара. Бүгенге көндә махсус техника гына да 470 берәмлек исәпләнә. Җитештерүчәнлек тә югары. Быелның 9 аенда пландагы 0,607 урынына техниканы юлга чыгару коэффициенты 0,609 тәшкил итте.

**- Производство базаларының киңәюе дә аз роль уйнамыйдыр инде.**

- Әйе, һичшиксез. Безнең идарәнең базалары «сибелгән». Норлаттан 70 километр ераклыкта булган Күтәмәдә дә, бераз гына якынрак Андреевкада да бар алар. Барысында да эшләүчеләр өчен тиешле хезмәт шартлары, техника өчен ышанычлы саклау урыннары тәэмин итәргә омтылабыз. Андреевкада автотранспорт өчен бер дигән гараж салып куйдык. Күтәмәдә төзеләторганын да көз азагында файдаланугa бирергә ниятлибез.

( Ахыры 2 нче биттә).

## Кар төшкәнче өлгерәсе иде

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Кичәге көнгә шикәр чөгендере 5161 гектар мәйданнан казып алынды. «Игенче»дә татлы тамырны казу соңгы гектарларда бара, «Киекле», Кузнецов исемендәге хуҗалыкларда да бу эш бетүгә таба инде.

Шикәр заводына безнең район хуҗалыкларыннан 23 октябрьгә 53 мең тоннадан артыграк чимал керде. Тик соңгы бер көндә ташылганы ике мең тоннага да тулмады. Шунысы куанычлы, соңгы вакытта чөгендер күзгә күренеп чистарак килә башлады. «Төрнәс» хуҗалыгы чөгендер сату планын 133, заводның үз ярдәмче хуҗалыгы 126 процентка үтәде инде. «Кондырча»да планның өч чиреге, «Рассвет»та 70, Хафизов исемендәге хуҗалыкта 67, Кузнецов исемендәгедә 60 проценты тулды. Соңгы бер көндә иң күп чөгендер дә алардан керде.

Бөртеккә калдырылган кукурузның мең гектардан артыгы җыеп алынды. Бу эшне «Таң»да, сөт - май комбинатының ярдәмче хуҗалыгында да тәмамладылар инде. Әмма ун хуҗалыкта кукуруз суктыруга тотынмаганнар диярга була әле.

## Район хәбәрләре: яңалыклар, фактлар

### Чөгендердә - шәһәрлеләр

Явым - төшемле көз чөгендер җыюда зур кыенлыклар тудыра. Җәй буе үстергән, тәрбияләгән уңышын авыл хуҗалыгы хезмәткәре үз көче белән генә җыеп бетерә алмый. Менә шул чакта шәһәр халкы аңа ярдәмгә килә дә. Шулай Норлаттан да көн саен 6 - 7 автобус пассажирларын көтеп ала. Башлыча 99 нчы СПТУ укучылары, саклык банкы, салым инспекциясе, район үзәк шифаханәсе, АТП хезмәткәрләре дә актив йөри авыл кырларына. Район хезмәт һәм мәшгульлек бюросы тарафыннан оештырылган 60лап кешедән торган группа даими рәвештә иртән автобусларга төялеп Норлаттан чыгып китә. Заман чиренә әйләнгән эшсезлек проблемасына дучар ителгәннәр өчен дә, уңышы кырда калу куркынычы янаган хуҗалык өчен дә файдалы. Шулай ук мәктәп укучылары да елдагыча бу мөһим эштән читтә калмыйлар. Аеруча шәһәрнең 1нче, 3 нче, 8 нче мәктәпләреннән авылларга актив йөриләр. Ә ярдәм көтүче хуҗалыклар аз түгел: «Игенче» КХАсына һәр көнне 60 - 70 кеше бара, «Заветы Ильича», «Москва», «Әлмәт» хуҗалыклары, Кизләү, Богдашкино авыллары кырлары шәһәр ярдәмчеләрен көтеп алалар.

Транспорт белән тәэмин итүдә АТП зур өлешен кертә. Шулай ук «Норлатнефть» НГДУсы, «Татнефть - Норлатнефтеразведка» да читтә калмый.

### Су килде, җылы су!

Нефтьчеләрнең яңа микрорайоны халкы җылы суга әллә ни тиенә алганы юк. Кышкы сезонда график белән биреп алалар иде дә аны, шуның белән бетә иде бу рәхәтлек. Хәер, салкын суы да вакытлап кына бирелгәндә әллә нигә өмет тә итеп булмый шул.

Быел җылы су рәхәте озаккарак сузылыр дигән өметтә яши микрорайон халкы. Салкын суның краннарда даими булуы, җылылык хуҗалары вәгъдәсе ныгыта бу ышанычны. Ә краннардан су шалдырап ага - җылы су!

### МӘКТӘП ЮБИЛЕЙ ҮТКӘРӘ

***Норлаттагы 2нче номерлы рус- татар мәктәп-гимназиясе шимбә көнне район мәдәният йортында үзенең 60 еллык юбилеен үткәрергә җыела.***

Бай тарихы,гүзәл традицияләре булган уку йорты бу көнне үткәне,киләчәге турында эчкерсез сөйләшү алып барачак.Бәйрәмдә мәктәпне төрле елларда тәмамлаган укучылар да тансык кунак булырлар дип көтелә.

### Игътибар: эзлибез

**Район эчке эшләр бүлегенең уголовный розыск бүлеге гражданнарны билгесез ир - ат мәете шәхесен фотография аша ачыкларга булышуын сорый. Яше 35 - 45 чамасы, урта буйлы, аксыл кыска чәчле. Быелның мартында Вахитов урамындагы йорт подвалында табылган иде. Хәбәр итү өчен телефоннар: 2 - 12 - 32, 2 - 19 - 02, 2 - 11 - 25 яки 02 аша дежур частька.**

# TV

## ПОНЕДЕЛЬНИК, 27 октября

**ТАТАРСТАН**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.10 Балалар өчен "Тамчы"
17.25 "Бизнес TV"
18.00 "Прямая связь"
18.45,20.45 "Җиһан" хәбәрләр
19.00 "Замандаш" циклыннан
19.45,21.45 Новости
20.00 "Баскетбол, мы тебя любим"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "СТАЛКЕР". 1 - я серия
22.25 "Карт - бланш"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 1.05 Новости
9.15, 18.20 "Девушка по имени Судьба"
10.00 Поле чудес
11.00 Здоровье
11.30, 19.35 Угадай мелодию.
15.20"Драконы подземелий"
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 "Космическая полиция".
17.05 "...До шестнадцати и старше".
17.30 "100 лет приключений". Сериал.
19.10 Час пик.
20.05 "Гибель галантного века".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 "Полтергейст-2".
22.50 "Серебряный шар".
23.40 "Похождения зубного врача".

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский"
7.35 Справочная "Медицина для вас"
7.40, 23.20 Вовремя
7.45 Монетный двор
8.00,11.00,14.00 Вести
8.20,0.10 Дежурная часть
8.35, 18.55 "Океан"
9.25 "Стронг" представляет
9.30 Компьютер!
9.40 Мультфильм
10.00,17.25 "Санта - Барбара"
11.20 L-клуб
11.50 Совершенно секретно
12.45 Свой дом
12.55 Сам себе режиссер
13.25 Парламентский вестник
13.55 Магазин недвижимости
14.20 Деловой автограф.
14.25 ТИ-Маркет
14.30 На пороге века
15.00, 0.30 Теннис "Кубок Кремля"
17.00, 20.00, 23.00 Вести
17.20 Православный календарь
18.20 Лукоморье
18.40 "История одного события"
19.50 Мой Пушкин
20.25 Подробности
20.45 Национальный интерес
21.15 "Взгляд сквозь тоннель"
23.25 Добрый вечер
1.00 Лестница в небо.

## ВТОРНИК, 28 октября

**ТАТАРСТАН**

7.00 - 8.00 "Чулпан".
17.30 Мультфильмы
18.05 "Әкиятләр бәйләме"
18.35 "Служба 01"
18.45, 20.45 "Җиһан" хәбәрләр
19.00 "Деловой Татарстан"
19.20 Телемост Казань - Набережные Челны
19.45,21.45 Новости
20.00 "Карт - бланш"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "СТАЛКЕР"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 "Гибель галантного века".
10.40 Смехопанорама
11.15 Домашняя библиотека
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
15.20 "Драконы подземелий".
15.45 Кварьете "Веселая квампания".
15.55 "Счастливый случай".
16.40 "Космическая полиция".
17.05 "...До шестнадцати и старше".
17.30 "100 лет приключений".
19.10 Час пик.
20.00 "Гибель галантного века".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.45 "Живет такой парень".
23.45 Хоккей. Евролига.
1.25 "Поворот винта"

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Стронг" представляет".
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 0.10 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Океан"
9.30 Деньги
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20, 11.48, 20.45 Национальный интерес.
13.25 Пульс.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "ТИ - Маркет".
14.30 Новое пятое колесо
15.00,0.30 Теннис. "Кубок Кремля"
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье.
18.40 "История одного события".
20.25 Подробности
21.20 "Первый троллейбус"
22.50 Мой Пушкин
23.25 Добрый вечер.
1.00 Звуковая дорожка.

## СРЕДА, 29 октября

**ТАТАРСТАН**

7.00-8.00 "Чулпан"
17.30 Мультфильмы
18.10 "Малая пресса - 97"
18.45,20.45 "Җиһан" хәбәрләр
19.00 "Авыл"
19.25 "Три бардовских аккорда"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Точка опоры"
20.20 "Иманым, дип сүз башласам..."
20.35 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Гусарская баллада"
22.35 "Мәрхәбә!"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.10 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 "Гибель галантного века".
10.40 "В мире животных".
11.15 Домашняя библиотека.
11.25 "Джентльмен-шоу".
15.20 "Волшебные истории".
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Космическая полиция".
17.05 "...До шестнадцати и старше".
17.30 "100 лет приключений".
19.10 "Золотая лихорадка".
19.45 "Гибель галантного века".
20.25,21.20 Футбол. Отборочный матч Чемпионата мира.
21.15 Время.
22.30 "Смертельная схватка".
0.30"Жерминаль".

**РОССИЯ**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Медицинский вестник".
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Итальянский ресторан."
9.30 "Деньги".
10.00, 17.25 "Санта-Барбара".
11.20,20.45 Национальный интерес.
11.50 "Абзац"
12.45 "Формула 900"
12.55 Слабо?
13.25 Федерация.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 ТИ - Маркет.
14.30Золотая картаРоссии.
15.00, 0.30 Теннис. "Кубок Кремля"
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье
18.40 "История одного события"
19.50 "Мой Пушкин".
20.25 Подробности.
21.15 "Подпольные Асы".
23.25 Добрый вечер.
1.00 Лестница в небо.

## ЧЕТВЕРГ, 30 октября

**ТАТАРСТАН**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.30 Мультфильм
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Вопросы из записной книжки"
19.25 "Эхо голоса твоего"
19.45,21.45 "Новости"
20.00 "ЦУМ приглашает..."
20.10 "Банк "Заречье" представляет
20.20 "ГАИ - информ""
20.35 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00. "Шанхай"

**ОРТ**

6.00 Доброе утро.
9.00 12.00 15.00 18.00 0.00 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00, 20.00 "Гибель галантного века".
10.40 "Пока все дома".
11.15 Домашняя библиотека.
11.30, 19.35 Угадай мелодию.
15.20 "Невероятные истории Джонни Квеста".
15.45 Волшебный мир, или Синема.
16.15 Лего-го!
16.40 "Космическая полиция".
17.05 "...До шестнадцати и старше".
17.30 "100 лет приключений".
19.10 Час пик
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.45 "Затерянный в Сибири".Х/ф.
23.50 "Каскадеры. Мир трюков".
0.35 "Путешественник".

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.35 "Стронг" представляет".
7.40 22.00 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 0.10 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Океан".
9.25 "Стронг" представляет.
9.30 Деньги.
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20,20.45 Национальный интерес.
11.50 "Городок".
12.20 Старая квартира. Год 1957.
13.25 "Люди и деньги".
13.15 "Формула 900"
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 ТИ-Маркет
14.30 Ваше состояние
15.00, 0.30 Теннис. "Кубок Кремля"
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье.
18.40 "История одного события".
20.25 Подробности
21.15 "Собачий нос".
22.10 Сам себе режиссер.
22.45 "Мой Пушкин".
23.25 Добрый вечер.
0.10 Дежурная часть
1.00 Кафе Обломов.

## ПЯТНИЦА, 31 октября

**ТАТАРСТАН**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.30 Мультфильм
17.45 "Деревенская история"
18.45,20.45 "Җиһан" хәбәрләр
19.20 "Дин һәм тормыш"
19.45,21.45 Новости
20.00 "В Госсовете Татарстана"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Җомга кән кич белән"
22.00 "Агым"
22.20 "Замандаш" циклыннан

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.05 "Гибель галантного века".
10.45 "Клуб путешественников".
11.35 Смак.
15.20 "На златом крыльце сидели"
16.35 "Улица Сезам".
17.05 "50 х 50".
17.30 "100 лет приключений":
19.15 Здоровье.
19.45 "Поле чудес".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.45 "Бабочка в серых тонах".
23.35 Взгляд.
0.35 "Казино".

**"РОССИЯ"**

7.10 "Дон Кихот Ламанчский".
7.40 23.20 Вовремя.
7.45 Монетный двор.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.20 0.10 "Дежурная часть".
8.35 18.55 "Океан".
9.25 "Стронг" представляет.
9.30 Деньги.
10.00 17.25 "Санта-Барбара".
11.20 Национальный интерес.
11.50 "Торговый дом "Ле Монти".
12.05 "Аншлаг" и К.
13.00 Репортер.
13.25 "Красная книга".
13.55 "Магазин недвижимости".
14.20 "Деловой автограф".
14.25 "ТИ - Маркет".
14.30 Парламентарий.
15.00, 0.30 Теннис. "Кубок Кремля"
17.20 "Православный календарь".
18.20 Лукоморье.
18.40 "История одного события".
20.25 Подробности
20.35 L-клуб.
21.10 "Собачий нос".
22.05 Слабо?
22.50 Мой Пушкин.
23.25 Добрый вечер.
1.00 Лестница в небо.
1.30 Эх, дороги.

## СУББОТА, 1 ноября

**ТАТАРСТАН**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.00 "Храбрый портняжка"
17.30 "КВН - 97"
18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес TV"
19.35 Из "личной жизни..." дома
19.45 Новости
20.00 "Видеоспорт"
20.20 "Точка опоры"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
20.50 "Музыкаль сәхифә"
21.20 "Детству - быть!"
21.45 "Досье 02"
22.00 "Зәңгәр кыңгыраулар"

**ОРТ**

7.50 "Тайны Мадам Вонг".
9.20 "Ерш".
9.40 Лотто-Миллион.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 17.55 Новости.
10.10 Домашняя библиотека.
10.30 Утренняя почта.
11.05 "Каламбур"
11.40 Смак.
12.00 "Возвращение Третьяковки. История одного шедевра".
12.25 "Ералаш".
12.40 "Время желаний"
14.25 Очевидное - невероятное.
15.20 "Моя семья: красивые и некрасивые".
16.00 "Союзмультфильм" представляет.
16.55 Футбол. Чемпионат России.
18.50 "Спрут".
20.10 "Эти забавные животные".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
22.00 "Смерть ей к лицу".
23.55 "Дантон".

**"РОССИЯ"**

7.00 Утренний экспресс.
7.55 "Мак и Матли".
8.45 Мультфильм.
9.00 "Меморина".
9.30 Парламентский вестник.
10.00 Доброе утро, Страна!
10.45 "Ваш партнер".
11.00 Вести в одиннадцать.
11.20 Двойной портрет.
12.15 Крестьянский полдень.
12.40 Преодоление.(г.Сочи)
12.45 Федерация.
13.15 Новое пятое колесо.
13.45 "900 кубов".
14.00 20.00 Вести.
14.20 Телескоп.
14.50 "Встречная полоса".
15.05 Книжная лавка
15.30 "У всех на устах".
16.00 "Надо жить играючи".
16.15 "На дорогах России".
16.30 "Это Москва".
17.00 Вести про...
17.20 Бесконечное путешествие.
17.55 "Аджио" из балета" Щелкунчик".
18.00 Совершенно секретно.
18.55 Старая квартира. Год 1958. Часть 2-я.
20.35 Репортер.
21.10 "Бриллиантовая рука".
22.55 "Любовь с первого взгляда".
23.35 Программа "А".
0.05 Тихий дом.
0.30 Теннис."Кубок Кремля"
1.00 Живая коллекция.

## ВОСКРЕСЕНЬЕ, 2 ноября

**ТАТАРСТАН**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.40 Мультфильмы
18.00 "Хәерле сәгатьтә"
19.00 "ТОН"
19.40 "Автокалейдоскоп"
20.00 "Телебуклет"
20.15 "Әлли - бәлли - бәү"
20.35 "Зәңгәр кыңгыраулар"
21.35 "Аккош күлендә"
22.05 "СИРЕНЫ"

**ОРТ**

7.55 "Мы двое мужчин".
9.15 Мультфейерверк.
9.55 Спортлото.
10.00 15.00 0.20 Новости.
10.10 "Непутевые заметки"
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Служу России!
12.30 "Играй, гармонь любимая!"
13.00 Сельский тележурнал.
13.25 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.20 Смехопанорама.
15.20 Клуб путешественников.
16.05 Футбольное обозрение
16.35 "Земля до начала времени".
17.45 "Ералаш".
17.55"Колесо истории".
18.50 "Кубанские казаки"
20.50 Киноафиша.
21.00 Время.
21.45 "Коммандо".
23.30 "Приглашение к музыке".
0.10"Телохранитель".

**"РОССИЯ"**

7.55 "Мак и Матли".
8.50 Мультфильм.
9.15 Диалоги оживотных
9.30 Присяга.
10.00 Доброе утро, Страна!
10.45 "Компьютер!"
11.00 Вести в одиннадцать.
11.20 Русское лото.
12.00 Пульс.
12.30 "День без меня".
12.45 "Люди и деньги".
13.15 "Формула 900".
13.30,14.20 Теннис. "Кубок Кремля"
14.00 Вести.
16.05 "Чемпион мира".
17.35 "Довгань-шоу".
18.00 Волшебный мир Диснея.
18.55 "Аншлаг" и Ко.
20.00 Зеркало.
21.10 Футбол без границ.
21.41 "Абзац"
22.40 "Готика"
0.10 Русский бой.
1.10 У Ксюши.
1.40 Подиум Д"Арт.

## Җәүдәт Камалов



# Кычытканлы авылы тарихыннан

**( Дәвамы. Башы 119-120 саннарда).**

1950 елда мәктәп 7 еллык, 1959 елда 8 еллык, 1986 елда урта мәктәп итеп зурайтылды. Мәктәп директоры булып озак еллар Яруллин Замир Ярулла улы булган көчен һәм сәләтен бирeп эшләде. 1989 - 97 елларда үз авылында укып 117 бала урта белем алды.

1970 елга авылдан 40 югары белемле белгечләр чыкты. 52 егет һәм кыз төрле урта махсус белем алдылар.

Авыл халкының хуҗалыктагы төп эш төрләре - кырчылык һәм терлекчелек, өлешчә умартачылык. Туфраклар күбесенчә урман асты - көлсу булганлыктан, уңдырышлы кара туфракка таләпчән бәрәңге, карабодай, тары кебек культуралар игелми. Бөртеклеләрнең дә уңышы зур түгел. Соңгы елларда алдынгы агротехнология алымнарыннан файдалану, җирне һәм минераль ашламаларны дөрес куллану нәтиҗәсендә бөртеклеләрнең, шикәр чөгендеренең уңышы күтәрелде.

40 - 60 елларда авылда промысел артеле яшәп килде. Ул сугыш елларында хәерчелеккә төшкән халыкны иң тәҗел нәрсәләр белән тәэмин итеп торды. Аяк киемнәре тегә, киез итек баса иделәр. Шкаф - шифоньерлар, комодлар, урындыклар кебек халыкка кирәк нәрсәләрне җитештерәләр, чагыштырмача арзан бәягә такта, әзерләгән утын саталар иде. Кызганычка каршы, Н.С.Хрущевның реформаторлык эшчәнлеге нәтиҗәсендә бу кирәкле хуҗалык тармагы юк ителде. Артель белән озак еллар дәвамында Галиуллин Исхак Галиулла улы, сугышта катнашучылар, сугыш инвалиды Садыйков Әгъләм Фәтхетдин улы һәм Мусин Гәрәй Ибраһим улы намус белән җитәкчелек иттеләр.

Авыр елларда авыл халкының мәнфәгатен кайгыртып соңгы көннәренә кадәр авыл Советы рәисе булып ярдәмчел, киң күңелле Нургалиев Фаикъ Нургали улы эшләде.

«Татарстан» күмәк хуҗалыгы рәисе булып Билданов Замир Шамил улы (1965 - 1987) һәм Нуралиев Җәүдәт Заһит улы (1987 - 1996) эшләгән елларда капиталь төзелеш эшләре киң колач ала, хуҗалыкның материаль нигезе ныгый, авыл халкының яшәү шартлары яхшыра. Җегәрлеге елына бер миллион данәлек кирпеч заводы төзелде (1973). Терлекчелек өчен 11 таш бина корылды. Техника саклау өчен автотранспорт гаражы, ремонт базасы мастерское аякка басты, минераль ашламалар һәм фураж саклар өчен амбар, орлык киптергеч, ике зур ябык ындыр табагы булдырылды. Ике катлы таш идарә бинасы (1982), 150 урынлы ике катлы таш урта мәктәп бинасы (1985), 200 урынлы ике катлы таш мәдәният йорты һәм китапханә (1989), мәдрәсә һәм таш мәчет (1995) биналары күтәрелделәр.

Авыл халкы торак өйләрен кирпечтән сала башлады. 1987 - 96 елларда 32 хуҗалык кирпеч өй салды. 1988 елда эшләп тәмамланган суүткәргеч халык тормышын кискен яхшыртты, җиңеләйтте. 1996 елда Норлат - Әлмәт - Базарлы Матак - Мурзиха трассасына чыга торган 7 чакрымлы юл асфальтланды. Газ кертү эшләре дәвам итә.

Халык мәнфәгате һәм культурасын үстерү турында кайгыртучанлык күрсәтү нәтиҗәсендә соңгы 10 елда яшьләрнең авылдан шәһәргә китүе тукталды.

Артка әйләнеп кайтып булса да шуны әйтеп узарга кирәк. Беренче империалистик сугышта катнашучылар авылда күп була. Хөснетдинов Шакирҗан, Йосыпов Закир, Гыйрфанов Исмәгыйль, Мингалимов Мирзасәлих, Насыйбуллин Минневәли, Яруллин Сәлимгәрәй, Мотаһиров Зәкиулла һәм башкалар сугыштан җирне крестианнарга бүлеп бирү, сугышны бетерү идеяләре белән сугарылып кайталар. Гражданнар сугышы башлану белән янә сугышка китеп, төрле фронтларда, Колчак, Деникин, Дутов, Махно һәм башкаларның гаскәрләре, Төрекстанда басмачылар белән көрәшәләр.

Харләмов Ибраһим, Хөсәенов Кәлимулла 25 нче В.И.Чапаев дивизиясендә, ә Насыйбуллин Минневәли, Зарипов Сәхипзада 28 нче В.М.Азин дивизиясендә сугышалар.

Революция алдыннан һәм аңардан соң Кычытканлы егете, Казанда гаскәри частьләренең берсендә комиссар булган Җиһангир Рәҗәп улы Рәҗәпов (1893 - 1919) авылга берничә мәртәбә кайтып крестианнар белән митинглар үткәрә, аларга властьның эшче - крестианнар кулына күчүе, җирнең крестианнарга бүленеп бирелүе, сугышны бетерү турында, кулакларга каршы көрәшкә чакырып ялкынлы речьләр сөйли.

**( Дәвамы бар).**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Норлат шәһәрендә яшәүче туганыбыз **Әгъдәс Гыйматдиновны** туган көне белән котлыйбыз. Нык исәнлек, тигез тату тормыш телибез.*

*Киң күңелле, кешелеклелегең өчен без сине яратабыз, бергә, бергә яшәргә ходай язсын.*

***Летфуллиннар.***

Норлатта яшәүче кадерле әниебез **Разыя Гомәр кызы Фәйзетдинованы** туган көне белән кайнар котлыйбыз. Аңа исәнлек - саулык, кәеф көрлеге, җан тынычлыгы телибез.



Сәламәт бул, гел шат яшә,
Бәхет кунсын күңелең түренә.
Барыбызга канат, терәк булып,
Талмый атла гомер үренә.

**Улы, кызы, килене һәм Фәнис.**


# Белдерүләр

## САТАБЫЗ

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2106**. Адрес: К.Маркс проспекты, 9 - 18.

***

**65 мең км. юл үткән, әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21013**. Тел.: 5 - 28 - 60.

***

**1988 елгы ВАЗ - 2108**. Адрес: Советская ур., 189 - 33, тел.: 65 - 8 - 31.

***

**1988 елгы ВАЗ - 2108.** Җиңүнең 50 еллыгы микрорайоны, 2 - 9. Тел.: 65 - 8 - 38.

***

**ВАЗ - 2105.** Каравыл Тавында (кирпеч заводы) Мандрейкинга мөрәҗәгать итәргә.

***

**«Урал» мотоциклы, «Муравей» мотороллеры.** Тел.: 2 - 25 - 88 (эш), 5 - 28 - 69 (өй).

***

**Беренче комплекттагы «Москвич - 412» двигателе һәм башка запас частьләр.** Тел.: 2 - 21 - 98.

***

**1980 елгы ВАЗ - 2103**. Тел.: 5 - 18 - 17.

***

**Җиңел автомобиль өчен кулланышта булган такчыч.** Тел.: 5 - 22 - 67.

***

**Капиталь ремонттан соң ПАЗ - 672 автобусы, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 34 - 42.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**1 бүлмәле фатирны өстәмә түләп 3 бүлмәлегә алыштырабыз (шикәр заводы һәм Кормыштан тәкъдим итмәскә).** Адрес: Дружба ур., 70 - 5, Тел.: 5 - 21 - 53, 17 сәг.тән соң.

***

Яруллин Ришат Галимханович исеменә документлар табучының (техпаспорт, машина йөртү таныклыгы) бүләк бәрабәренә түбәндәге адрес буенча иясенә кайтаруын сорыйбыз: Завод ур., 9 - 11.

***

**Предприятие, бюджет оешмалары, җирле үзидарә Советлары җитәкчеләренең газета - журналларга язылуны 1997 елның 1 ноябренә кадәр төгәлләүләрен сорыйбыз.**

Район элемтә узелы администрациясе.

***

**Яшь гаилә яшәп тору өчен барлык уңайлыклары булган 2 бүлмәле фатир эзли.** Тел.: 5 - 17 - 99.

***

**Октябрь районы МПП ЖКХ сына ашыгыч рәвештә 4, 5 разрядлы газ һәм электр белән эретеп ябыштыручылар кирәк. Торак бирелә, түләү - штат расписаниесе буенча.** Тел.: 2 - 10 - 98, 2 - 21 - 71.

***

**Ашыгыч рәвештә яңа планировкалы 2 бүлмәле фатир сатып алам (шикәр заводыннан тәкъдим итмәскә).** Тел.: 5 - 16 - 81 (18 сәг.тән соң), 2 - 22 - 51 (эшнеке).

***

**Арзан бәягә сыйфатлы итеп йортлар, гаражлар төзибез.** Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗип.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7 ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


# СЕЗНЕҢ ТАБИБЫГЫЗ

***Соңгы вакытта безнең редакциягә үләннәрдән әзерләнгән «Наркодел» шифалы чәе турында язуыбызны үтенеп күпләр мөрәҗәгать итәләр. Ул алкогольне күпләп кулланучыларда яшел еланнан баш тарту яки аны кискен кыскарту бирергә мөмкин. Аның турында сөйләүләрен үтенеп без «Маги - фарма» наркологик фирмасының баш табибы В.И.ЧЕРНЫШОВКА мөрәҗәгать иттек.***

Үз сүземне мин бер хаттан өзек китереп башламакчы булам: «Сезгә Анапа шәһәреннән А.яза. Безгә булышуыгыз өчен зур рәхмәтлемен. Улым 1992 елның гыйнварыннан чәй эчә башлады, аракы эчүне ташлады, үз - үзен тыныч тота, гаиләсе белән мөнәсәбәте дә яхшырды». Безнең фирма адресына шундый хатлар күпләп килә.

«Наркодел» нидән гыйбарәт соң? Бу - элек - электән борынгы Русьта эчүчелеккә каршы кулланыла торган халык рецептларына нигезләнгән үлән чәе. Аның составына Русиянең экологик чиста районнарында үсә торган үләннәр керә. «Наркодел» тәэсире астында авыруларда спиртлы эчемлекләргә тартылу бетә, аларга карата битарафлык тота. Кайчак ул шул дәрәҗәгә җитә ки, кешенең кулы рюмкага үрелгәндә дә ул аны эчә алмый. «Наркодел»нең уникаль үзенчәлеге нәкъ шуннан гыйбарәт тә. Әмма чәйнең тагы бер кыйммәтле сыйфаты бар. Ул кара эчү белән эчкән, әмма үзләрен эчкече дип санамаган һәм шул сәбәпле дәваланудан баш тарткан кешеләргә дә уңыш китерә. Мондый очракта әлеге кешенең туганнары «Наркодел»ны нинди дә булса сыек блюдага аның ризалыгы - теләгеннән башка салалар. Өстәвенә «Накродел» алкоголь куллануадан туган агрессивлыкны да киметә, бу да мөһим.

«Наркодел»ны озак вакыт, ким дигәндә бер ел дәвамында тәүлеккә бер тапкыр кулланырга кирәк. Ул зыянсыз, ашказаны һәм уникилле эчәк язвасын дәвалауга булыша, бавыр функцияләрен нормальләштерә.

Туганнары һәм танышлары бездән чәйне эчүче кешенең үзеннән башка алып та куллана алалар, кирәк чакта безнең фирма белгечләре белән киңәшергә онытмасыннар. 1 төргәк чәй 20 көн кабул итәргә җитә.

Сүзебезне йомгаклап, чәйнең зыянсыз, гигиеник сертификатка ия булуын әйтәсебез килә. Аны күптөрле авырулардан интеккән, шул сәбәптән нииндидер дәвалау методлары кире кагылган кешеләр дә куллана алалар.

Чәйне «МАГИ - ФАРМА» фирмасында яки аның региональ вәкиллегендә сатып алырга мөмкин, анда безнең фирманың таныклыгы булуы шарт.

Түләү юлы белән чәй җибәрелми. Норлатта «Наркодел» чәен 27 октябрь көнне район мәдәният йортында 11 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр алырга мөмкин. Лицензия номеры 000102, Мәскәү шәһәренең фармация департаменты тарафыннан 28.09.95 елда бирелгән.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.